# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге составына керүче Югары Тәкәнеш торак пунктында 2023 елга үзарасалым кертү турында

№ 7 27 октябрь 2022 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчыстатьялары, «Татарстан Республикасындаҗирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нчестатьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясынигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлегенең Югары Тәкәнеш торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Тәкәнеш авыл җирлегенең Югары Тәкәнеш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәт итүгә чакырылган гражданнар кала, 2023 елда 500(биш йөз) сум күләмендә үзарасалым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Югары Тәкәнеш торак пунктындагы җирле әһәмиятле юлларны кардан чистарту һәм грейдер белән тигезләү;
- Югары Тәкәнеш торак пунктында урамнарны яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, урам яктырткычларының лампочкаларын алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).
- Югары Тәкәнеш торак пунктында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (сатып алу, иске су торбаларын алмаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү)

3.Әлеге карарны Түбән Тәкәнеш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе Р.Ж.Хәмизуллин